ISSN 0868-4545



Салават күпере



Вәгъдә

Рөстәм Мингалим

Салкын айлар – кыш икән,
җылы айлар – җәй икән.
...Шулай диләр кешеләр,
шулай, имеш, электән.

Алай гына түгел шул,
берзаман болай булган.
Җәй исемле кыз булган,
Кыш – чая малай булган.

Чая малай – ак тунлы:
хәтерләткән аюны!
Җәйнең җилфер-күлмәге
чигүле дә каюлы...

...Ялгыш кына Кыш та Җәй
очрашканнар беркөнне.
Шуннан нәрсә булганмы?
Икәү бергә киткәннәр!



© "Салават күпере", 2002 ел




Кем ничектер, мин үзем
каршы түгел бу эшкә.
Дус калырга мәңгегә
алар вәгъдә бирешкән!

Электән үк, шул чактан
алар бергә йөриләр:
икәү бергә – туңалар,
икәү бергә – эриләр.


Дөм караңгы төндә дә
югалтмыйлар бер-берсен.
Онытмыйлар
берсе дә
бер-берсенә
вәгъдәсен!

Ул кыз белән малайны
сез күрмисез, мин күрдем.
Миңа алар елмаеп,
күз кысып та өлгерде.

Чая малай – ак тунлы,
хәтерләтә аюны!
Җәйнең җилфер-күлмәге
чигүле дә каюлы.



Рәссам Лилия ЗОЛОНДИНОВА





Ләбиб Лерон

Алдар Хәким

*Рәссам
Фәрит Муллахмәт*

Шалтмылтфильм

Илләр гизеп йөрмәсәм дә
Беләдер мине һәркем:
Фамилиям – Габсаматов,
Исемем – Миңлехәким.

Сезнең өй түбәсе – салам,
Безнеке калай инде.
Сүз эзләп кесәгә кермим –
Мин шундый малай инде!



Тумыштан ук бик гайрәтле,
Көчле малай мин үзем:
Сазга баткан тракторны
Чыгардым мин берүзем!



Мактану ул – яман гадәт,
Алдашуы – бигрәк тә...
Пропеллер ясадым мин
Беркөн ике көрәктән!



Тәвәкәллек-җитезлектә
Узалмый мине беркем:
Әсма түти кәҗәсенә
Атланып йөрдем беркөн!



Авылдагы барча кеше
Бездән үлеп көнләшә:
Бишектәге минем энем
Сигез телдә сөйләшә!



Мин үзем дә вундеркинд бит –
Тугыз телдә сөйләшәм...
Утыз телдә җырлый алам,
Әгәренки теләсәм!



Сарык телен дә беләм мин,
Тавык телен дә беләм.
Кирәк икән чичичиләп,
Тычкан телендә көләм!



Әллә-әллә нәрсәләргә
Җитәрлек минем хәлем –
Беркөн күккә менеп төшеп,
Яңгыр яудырдым әле!



Тагын беркөн күккә менеп,
Йолдызлар чүпләп төштем.
Соңгы йолдызны өзгәндә
Уч төбем яман პеште...



Мактану ул – яман гадәт,
Алдашуны әйтмим дә...
Күккә очу берни тормый
Габсаматов Хәкимгә!



Бер генә кимчелегем бар:
Сүзне кире боралмыйм.
Мактануын мактансам да,
Алдашмыйча торалмыйм.



Зиннур Хөснияр

Тукран тәүбәсе

Бер дә бер көнне Тукран гадәттәгечә эшкә кереште. Усак агачын корт баскан, агачның тәннәре сызлана. Ул Тукранны үзе чакыртып алды. Рәхмәт инде Тукранга, сүз тыңлап килде. Тук та тук, тук та тук. Тукранның «балта» тавышыннан урман эче яңгырап тора. Бу тавыш өнендә йоклап яткан Аю-Әппәснең ачуын китерде. Ул Тукранны үз янына дәшеп алды да: «Тагын тавышланып йөрсәң, мин сине урманнан кудырам!» – диде. Тукран урман патшасы Аю-Әппәстән курыкты, бүтән тукылдатмаска булды. Шулай бер көн узды, икенче көн, өченчесе дә үтеп китте. Тукран тукылдатмый, өендә генә утыра. Урман эче тып-тыныч.

Дүртенче көн дигәндә таң белән урманда тавыш купты. Песнәкләр, кызылтүшләр, саесканнарның бик каты тамаклары ачкан, алар барысы да ачтан үләрлек хәлдә. Менә җыелышып Тукран янына килделәр һәм ялварырга керештеләр:

– Тукран агай, зинһар, безне ачтан үтермә. Зинһар, тизрәк тукылдата башла! – дип ялынды алар. Тукран боларны кызганды инде. Һәм корт баскан бер усак агачын тукылдата башлады.

Аюның моңа тагын ачуы килде. Ул Тукранны чакыртып алды да: «Тагын тукылдатасыңмы?» – диде. Куркып калган Тукран: «Юк, Аю агай, башка тавышланмыйм!» – диде. «Тәүбә итәсеңме!» – диде усал Аю-Әппәс. «Тәүбә! Тәүбә!» – диде Тукран.

Шул рәвешле бер көн узды, икенче көн. Өченче көн дигәндә таң белән урманда янә тавыш чыкты. Агачларны кортлар кимерә, алар сызланып ыңгырашалар, кошлар ачтан үлә. Бу тавышка Аю-Әппәс тә уянды һәм тиз арада җыелыш җыйды. «Ни булды?» – дип сорады ул.

Аңа хәлне аңлатып бирделәр. Аю тиз генә Тукранны чакыртып алды һәм: «Ярый, тукылдат инде. Син күп файда китерәсең икән бит!» – диде. «Юк! – дип, аңа каршы төште Тукран. – Мин тәүбә иттем! Хәзер сүземне боза алмыйм!» – диде.

Аю-Әппәс елмаеп куйды һәм: «Син мине гафу ит инде, Тукран дус. Ә тәүбәгә килгәндә... әйдә ул «Тукран тәүбәсе» генә булып калсын. Оныт инде син аны», – диде.

Шуннан соң Тукран янә эшкә кереште. Урман аңа рәхмәт әйтте.



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ



Чал тукран

Тукран бөҗәкләр белән туклана. Һәм җылы якка да очып китми. Туган җирендә – урманда – кышлый.

Чал тукранны Татарстанның Яшел Үзән, Биектау, Лаеш, Минзәлә, Лениногорск, Әлмәт районнары урманнарында очратырга мөмкин.




«Во» әби

Миңа әти алды туп –
Дуслар җыелды бик күп.
Киттек шуннан урамга,
Бергәләп туп уйнарга.
Уйнадык бик шәп кызып –
Тузаннар торды тузып.
Кинәт безнең кара туп
Әби бакчасына – «туп!»
Әби бакчада иде...
Хәзер нишләтер инде?!
Улмы? Ул тупны алды,
«Во» дигән «подача» биреп,
Безнең һушларны алды.

Булат Шәфигуллин.
Минзәлә.



Таңсылу Миңнегулова,
Актаныш районы.



Эльвира Баһаветдинова,
Казан.



Эльмира Галимова,
Яңа Чишмә районы.



Гөлназ Тимербулатова,
Нурлат районы.

Тукай бәйрәме

Әйдәгез, журналның бу битендә Тукай шигырьләре белән бергәләшеп бәйрәм итик. Бәйрәм булгач, әлбәттә, аның төрле кызык-мызыгы да булыр инде, яме.

Габдулла Тукай: «Гали белән Кәҗә» шигыре.

«Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән».

Шушы урында шып туктыйк. Һәм исәп-хисап алып барыйк әле. Галинең мөгезе юк, ә кәҗәнең ничә мөгезе бар?

Галинең ике аягы, ә кәҗәнең ничә аягы була?

Бер кәҗәдә ничә аяк, ике кәҗәдә ничә аяк була?

Ә өч кәҗәдә барысы ничә мөгез һәм ничәләп аяк булыр?Исәплә дә – җавабын әйт, яме.

«Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый – сакалын селкетә».

Рәхмәт укый белгәч, акыллы кәҗә була инде ул, әйеме?Ә син рәхмәт әйтә беләсеңме?Рәхмәт дип кайчан һәм кемгә әйткәнең бар?Шуларны искә төшер дә безгә язып җибәр, яме.

Тукайның «Гали белән Кәҗә» дигән шигыре шуның белән тәмам. Ә безнең сүз бетмәде әле. Тагын саныйсы бар: кәҗәнең сакалында ничә бөртек йон (кыл) бар?Әгәр дә мәгәр шушы сорауга җавап таба алсаң, син беләсеңме кем буласың?Кем буласың, йә, үзең әйтеп кара инде...

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Табышмак әйтәм.

Тукайның «Яңгыр» шигыре буенча.

Былчыракта яңгыр артыннан балалар йөгерешә,
Кычкыралар: «Җиргә, дип, алтын төшә!»
– Шауламагыз, балалар! Без җыярбыз барчасын,
Тиз ул алтыннарны амбарга төярбез барчасын.
Тик җыярбыз юл буе шыгрым тулы йөкләр көе,
Бар келәтләр туп-тулы Хуш исле орлыклар көе.

Тукай шушы урында шигырьгә нокта куйган. Ә без аңа аңлатма биреп карыйк әле. Яңгыр ява. «Алтын ява!» дип балалар йөгерешә. **Шагыйрь абый яңгырны нигә алтын белән чагыштыра? Шуны аңлатып бирә аласыңмы?**



Кызыклы шәкерт

Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
– Ник газаплыйсың болай син мине, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.
Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.
– Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар – эш белү уңайсыз ул!

Әгәр укый белсәң, шигырьне яхшылап укып чык. Әле мәктәпкә кермәгән булсаң – өлкәннәр сиңа кычкырып укысын. Менә Тукай бабай маэмай турында шундый шигырь язган. Моңа күп гомерләр узган. Маэмай зур үсеп җиткән. Ә күршедә бер кечкенә малай бар икән. Ул үзе кечкенә ди, ә үзе бик ялкау ди. Шуннан соң безнең маэмаебыз шигырьне үзгәрткән. Әйе, әйе, үзгәргәннән соң шигырь маэмай турында түгел, малай турында килеп чыккан. Менә йә үзең укы, йә тыңлап кара.

Әйдәле, малай! Өйрән син, ике аягыңда тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
– Ник газаплыйсың болай син мине, маэмай, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.
Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем йоклыйсым килә;
Шул караватта ятасым, шунда ауныйсым килә.
– Ах, җүләр малай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул;
Картаеп каткач буыннар – эш белү уңайсыз ул!

Йә, әйт әле, бу шигырь маэмай турындамы, әллә малай турындамы?



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Путин кайда йөри яки песи, песи, пескәем...



Былтыр журналыбызның апрель санында «Былтырның хисабы»н биргән идек. Мөселман календарена карасак, менә тагын бер ел үтеп киткән. Нигә быел да исәп-хисап ясамаска? Ничек итепме? Әлбәттә инде, мәшһүр Тукаебыз язган «Былтырның хисабы» калыбында.

Былтыр Казаннан 9 яшьлек Айрат Нуретдинов «Васильево» шифаханәсендә, көнгә 6 тапкыр ашатуларына карамастан, нибары 700 граммга арткан. Аның каравы, кемдер таշлап киткән мәче баласы ускән-көрәйгән. Малай ашлаганы һәркөнне аның белән бүлешкән.

Былтыр телевидениенең ОРТ каналы аша күрсәтелә торган «Утренняя звезда» тапшыруында татар җырлары әледән-әле яңгырап торды. Афәрин, Чаллы малайлары! Афәрин, Бөгелмәдән «Чишмә» ансамбле кызлары! Сез моңнарыбызны бөтен Рәсәйгә ирештердегез.

Былтыр Казандагы 71 нче мәктәп укучысы 9 яшьлек Адилә Хөснуллина тәүлекнең 24 сәгатьтән түгел, ә 25 сәгатьтән торуын исбатлады. Дзюдо белән шөгыльләнүче, музыка дәресләренә дә йөрергә вакыт табучы бу кыз: «Моның өчен иртән 1 сәгатькә иртәрәк торырга кирәк», – ди.



Былтыр шагыйрь Ркаил Зәйдулла – 7 яшьлек улы Баязитка Казан Кремлен күрсәтә. Президентның шунда эшләвен әйтә. Кайтканда, рәхмәт төшкере, Шәймиев боларга үзе очрый бит. Ул малайдан хәл-әхвәл сораша, аның белән фотога да төшә. Тиздән Баязитка Мәскәү Кремлен дә күрергә насыйп була. Кызыл мәйданда шактый йөри торгач, малай әтисенә әйтеп куя:

– Нишләптер Путин күренми. Бүген эшкә килмәгән, ахры.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Илсөяр Иксанова

Атна

Кадерле дусларым!

Без сезнең белән вакыт илендә шактый сәяхәт итәбез инде, әйеме? Бу сәяхәттә без сәгатьне өйрәндек, тәүлекнең ни икәнен белдек. Бүген исә без атна турында сөйләшербез. Атна көннәренең һәркайсының үз урыны бар. Алар рәсемдәге вагоннар төсле беркайчан да бер-берсен уза алмыйлар.

Атна көннәре

Якшәмбе **Воскресенье** (русча) Sunday (инглизчә)


– Барыбызның да бик яраткан көне. Икенче төрле без аны ял көне дип атыйбыз. Бу көнне без барыбыз да – әти-әни, балалар – бергәләп ял итәбез, кунакка йөрибез. Якшәмбе – христианнар өчен изге көн. Инглизчәсе Кояш сүзеннән алынган.

Дүшәмбе **Понедельник** Monday

Атнаның икенче көне. Иске рус телендә якшәмбе (воскресенье) – «атна», дүшәмбе (понедельник) – «атнадан соң» дигән мәгънәне аңлата. Яңа эш атнасы башлана.

Сишәмбе **Вторник** Tuesday

Атнаның өченче көне. Инглиз телендәге атамасы англосак-



сонның сугыш Алласы Тива исеменнән алынган.

Чәршәмбе **Среда** Wednesday

Атнаның дүртенче көне. Атна уртасы. Бу көнне инглизләр англосаксон Алласы Воданны искә алалар.

Пәнҗешәмбе **Четверг** Thursday

Атнаның бишенче көне – атна кич. Инглиз телендәге яңгырашында күк күкрәтү Алласы Тора тавышы ишетелә.

Җомга **Пятница** Friday

Мөселманнар өчен изге, җыелып намаз укый торган көн. Инглизчәсе скандинавларның мәхәббәт алиһәсе Фригги исеменнән алынган.

Шимбә **Суббота** Saturday

Яһүдиләр өчен изге көн. Инглиз телендәге атамасы Сатурн планетасы белән бәйле.

Күргәнебезчә, атна җиде тәүлектән тора. Ә нишләп нәкъ менә җиде? Бу хакта алдагы сәяхәтебездә сөйләшербез.



Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА

Җавабын уйлап тап

Булат бер мәртәбә: «Әни» дип эндәшкәнче, Зилә апасы биш тапкыр «Мам!» диярга өлгерә. Шулай да әниләре әүвәл Булатның сүзенә колак сала. Зиләне ишетмәгәнгә салыша.

Әни нигә шулай эшли? Җавабын уйлап тап.

Маратка ярдәм ит

Марат мәктәптән кайтты да, киемнәрен алыштырганда ук, автоматтан аткандай сөйли башлады.

Марат сөйли: «Бүген училка өйгә заданиеләрне күп бирде. Ә беренче уроктан соң вахтер апа звонок бирергә оныткан, переменкага соңга кала яздык. Әни, бүген по математике «пятерка» минем. Домашнее заданиедән».

Әнисе сорый: «Ә туган теленнән ничәле билгесе куйдылар, улым?»

Марат дәшми.

Марат әнисенең соравына нигә җавап бирми икән. Син шуны беләсеңме? Ә син аңа туган телдән нинди билге куяр идең?

Маратның сөйләгән сүзләрен татарча дөресләп чык.





Рәссам Фәридә ЗӨЛКАРНӘЙ

Бутамышлар

Шагыйрь Габдулла Тукай фашистларны бер дә яратмаган. Ул аларны тәнкыйтьләп шигырьләр язган. Шуңа күрә гитлерчылар аны әсирлеккә алганнар һәм төрмәгә ябып куйганнар.

Бу хәбәр Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә ишетелгән. Ул күп уйлап тормаган, чанасына 3 овчарка җиккән дә гитлерчылар янына киткән. Шәймиевне күргәч, немецларның котлары ботларына төшкән. Алар шундук Тукайны тоткынлыктан азат иткәннәр.

Тукай үзенең дустына рәхмәт әйткән – сакалын селкеткән. Сакал селкенүгә урамда бик көчле җил чыккан. Ул каты җил Президент Шәймиевнең эшләпәсен очыртып киткән. Эшләпә җил белән очып-әйләнеп бик озак йөргәннән соң – тәмам алҗыган. Һәм ял итәргә уйлаган. Ул туктаган урын Кремль эчендә икән. Менә берзаман ялтырап кояш чыккан. Эшләпә ялга туктаган урында зур, мәһабәт мәчет үсеп чыккан. Моны күреп, Казан халкы чабышып килеп җиткән. Алар авызларын ачып карап торганнар да «Кол Шәриф!» дип кычкырып җибәргәннәр. Һәм мәчетнең исеме Кол Шәриф булып калган.

Укучым!

Бу хәлләрне сөйләүче тәмам буталып беткән түгелме соң? Дөреслэп чык әле син аны һәм «Салават күпере»нә язып җибәр.







– Уйлыйсыздыр: «Бу кыз нигә
Утыра авыз җырып?»
Бу – минем көлүем түгел,
Бу – минем тәүге җырым!

(Аксубай, Иске Кармәт)



– Сине үлеп яратканны
Беләсең, сизеп торам...
Ялгыш агачны кочканмын,
Мин аны син дип торам!

(Казан)




– Чәй-нигъмәтем күптән әзер,
Аш пеште әле генә...
Яраткан оныкларыма
Оекбаш бәйлим менә.

(Апас, Каратун)



– Сизми калдым... Аһ, оннарым
Идәнгә үк сибелгән...
Токмачка камыр изүе
Түгел икән җиңелдән!

(Сарман)



– Айрат абый, әйтче, зинһар,
Ник кузгалмый вилсәпид!
– Белмим инде, энем, белмим...
Педаль-руль синдә бит!

(Башкортостан, Илеш)


Баштаткычлар



Бу әкияти, серле кошта ничә кошчык бар икән?

Баштаткычлар

Бу сурәттә күпме бияләй бар? Санап кара әле.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ.

Сәләвәт күпере

4(146) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Илдар НӘФИЕВ рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрияты комплексы» дәүләт унитар предприятиесе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 17.4.2002 ел.
Басарга кул куелды 17.4.2002 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 14915 данә. Заказ Б-213.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча

Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Апрель ае

Апрель, апрель...
Ярсып-кайнап,
Бозлар аккан ай ла ул.
Апрель, апрель...
Җылы яктан
Кошлар кайткан ай да ул.

Апрель, апрель...
Чәчкәләрне
Сагынып көткән ай да.
Апрель, апрель...
Халкыбызны
Тукайлы иткән ай да!

Апрель, апрель...
Ләйсән яңгыр
Яуган тәүге яз ае.
Апрель, апрель...
Җан-тәннәрне
Иркәләгән Наз ае!

